# КАРАР

## Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге составына керүче Иске Мокшино авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

№ 4 20 ноябрь 2025 ел

2025 елның 20 мартындагы 33 номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» ФЗ, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы «Мюд авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Мюд авыл җирлеге Советы ««Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында»05.11.2019 ел №99 карары нигезендә түбәндәге сорау буенча 2025 ел 11 ноябрендә узган җыен нәтиҗәләре беркетмәсе төзелде :

Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге Иске Мокшино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге;**

- Иске Мокшино торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (вак таш сатып алу, торак пункт юллары чокырларын ремонтлау, кышкы чорда юлларны кардан чистарту-эшләр өчен шартнамә буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)
- 

**Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидлар файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

- Иске Мокшино торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияләрне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, триммер сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)
- Иске Мокшино торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)
- Торак пункт чикләрендә җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (шартнамә буенча товарлар, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

«РИЗА» «КАРШЫ» «ТЫЕЛДЫМ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 168 граждан, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 96 граждан кертелде.

Ачык тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::
- «Риза»- 62 катнашучы тавыш бирде;
- «Каршы» -34 катнашучы тавыш бирде;
- «Тыелдым» 0 катнашучы тавыш бирде.
Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАРы:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге составына керүче Иске Мокшино торак пунктында гражданнар җыенын узды, нәтиҗәләре – дөрес дип таныргa.

2. Мәсьәлә буенча карарны кабул дип таныргa: Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Мюд авыл җирлеге составына керүче Иске Мокшино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан, көндезге формада белем алучы студентлардан, Россия Федерациясенең махсус операцияләрдә катнашучы хәрби хезмәткәрләреннән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә ризамы:

**Җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлегe;**

• Иске Мокшино торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау (вак таш сатып алу, торак пункт юллары чокырларын ремонтлау, кышкы чорда юлларны кардан чистарту-эшләр өчен шартнамә буенча түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

•

**Җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру, җирлек территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәү, социаль, инженерлык һәм транспорт инфраструктуралары объектларыннан һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидлар файдалана алуын тәэмин итү таләпләрен үтәү, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру:**

• Иске Мокшино торак пунктының башка территорияләрен төзекләндерү (җәйге вакытта территорияләрне чабу, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр, триммер сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү)

• Иске Мокшино торак пунктында урамнарны яктырту җайланмасы (товарлар, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен килешү буенча түләү)

• Торак пункт чикләрендә җәяүлеләр күперләрен һәм юл үткәргечләрен, гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау (шартнамә буенча товарлар, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)

3. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районы рәсми сайтында http://aksubayevo.tatar.ru урнаштырырга һәм рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/, Мюд авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга .

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Аксубай муниципаль районы
Мюд авыл җирлеге башлыгы Т.В. Зюзина